# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2007, № 7 (I өлеш); 2009, № 6; Ватаным Татарстан, 2011, 23 апрель), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**"Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

1 статья. **Татарстан Республикасы Хисап палатасы статусы**

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба — Хисап палатасы) Татарстан Республикасы тышкы дәүләт финанс контроленең даими эшләүче органы булып тора, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә һәм аның алдында хисап тота.

2. Хисап палатасы үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, әлеге Законга, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук тышкы дәүләт финанс контроле стандартларына таяна.

3. Хисап палатасы оештыру һәм функциональ бәйсезлеккә ия һәм үз эшчәнлеген мөстәкыйль башкара.

4. Хисап палатасы эшчәнлеге туктатып торыла алмый, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә дә.

5. Хисап палатасы юридик зат хокукларына ия, аның герблы мөһере һәм үз исеме язылган, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте төшерелгән бланклары була.

6. Хисап палатасының урнашкан урыны – Казан шәһәре.

2 статья. **Хисап палатасының бурычлары**

Хисап палатасының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларының күләмнәр, структура һәм максатчан билгеләнеш буенча керем һәм чыгым статьяларының үтәлешен тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) дәүләт акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген һәм максатчанлыгын билгеләү, Татарстан Республикасы дәүләт милке белән идарә итүнең һәм эш итүнең нәтиҗәлелеген тикшереп тору;

3) Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары, озак сроклы максатчан программалары, Татарстан Республикасы бюджет законнарының башка норматив хокукый актлары проектларына экспертизалар үткәрү;

4) Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларының билгеләнгән күрсәткечләреннән булган тайпылышларны анализлау һәм аларны бетерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләү;

5) банкларда һәм башка кредит оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары акчаларының законлы һәм үз вакытында йөрешен тикшереп тору;

6) Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлешенең барышы һәм уздырылган тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләрнең нәтиҗәләре хакында даими рәвештә мәгълүмат бирү.

3 статья. **Хисап палатасы эшчәнлегенең принциплары**

Хисап палатасы эшчәнлеге законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

4 статья. **Хисап палатасының составы**

1. Хисап палатасы Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары һәм Хисап палатасы аппараты составында төзелә.

2. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары вазыйфалары Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларына керә.

3. Хисап палатасында өч аудитор вазыйфасы билгеләнә.

4. Хисап палатасының штатлар саны Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән билгеләнә.

5. Хисап палатасында Хисап палатасы Коллегиясе төзелә, аның составына Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары керә.

6. Хисап палатасы аппаратының структурасын һәм штат расписаниесен Хисап палатасын тоту өчен каралган акчалар чикләрендә Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Хисап палатасы Коллегиясе раслый.

5 статья. **Хисап палатасы Рәисе**

1. Хисап палатасы Рәисе үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан алты елга билгеләнеп куела.

2. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатуралар күрсәтү хокукына түбәндәгеләр ия:

1) Татарстан Республикасы Президенты;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере.

3. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатуралар Хисап палатасының гамәлдәге Рәисе вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителәләр. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән очракта, әлеге вазыйфага кандидатуралар күрсәтелгән азат итү көненнән ике атна эчендә тәкъдим ителәләр. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына тәкъдим ителгән кандидатуралар кире кагылган очракта, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар ике атна эчендә яңа кандидатуралар кертәләр. Монда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатуралар тәкъдим ителергә йә башка кандидатуралар кертелергә мөмкин.

4. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кандидатуралар карау тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.

5. Хисап палатасы Рәисе:

1) Хисап палатасы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм законнар, Хисап палатасы Регламенты нигезендә аның эшен оештыра;

2) Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларын үтәүнең барышы турында квартал саен мәгълүмат, Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисаплар, башкарылган тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләрнең нәтиҗәләре хакында хисаплар бирә;

3) Хисап палатасы тәкъдимнәренә һәм күрсәтмәләренә имза сала;

4) Хисап палатасы аппаратының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрне һәм Хисап палатасы хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларын раслый;

5) дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар нигезендә яллаучы вәкиле вәкаләтләрен, Хисап палатасы аппаратының дәүләт граждан хезмәте хезмәткәрләре булып тормаучы хезмәткәрләрен эшкә алу һәм эштән азат итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

6) хуҗалык шартнамәләре һәм башка шартнамәләр төзи;

7) дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, Россия Федерациясенең, чит илләрнең контроль-хисап органнары, халыкара һәм башка оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Хисап палатасы исеменнән эш итә;

8) законнар һәм Хисап палатасы Регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6. Үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән Хисап палатасы Рәисе боерыклар һәм күрсәтмәләр чыгара.

6 статья. **Хисап палатасы Рәисе урынбасары**

1. Хисап палатасы Рәисе урынбасары үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан алты елга билгеләнеп куела.

2. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына кандидатура Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә.

3. Хисап палатасы Рәисе Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына кандидатураны Хисап палатасы Рәисенең гамәлдәге урынбасары вәкаләтләре чоры чыкканчыга кадәр бер айдан да соңга калмыйча тәкъдим итә. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасыннан вакытыннан алда азат ителгән очракта, әлеге вазыйфага кандидатура Хисап палатасы Рәисе тарафыннан күрсәтелгән азат итү көненнән ике атна эчендә тәкъдим ителә. Тәкъдим ителгән кандидатура кире кагылган очракта, Хисап палатасы Рәисе ике атна эчендә яңа кандидатура кертә. Монда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатура тәкъдим ителергә йә башка кандидатура кертелергә мөмкин.

4. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфасына кандидатураны карау тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.

5. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфаи бурычларын Хисап палатасы Регламенты нигезендә гамәлгә ашыра. Хисап палатасы Рәисе булмаганда һәм (яисә) аның кушуы буенча Хисап палатасы Рәисе урынбасары аның вәкаләтләрен үти.

7 статья. **Хисап палатасы аудиторлары**

1. Хисап палатасы аудиторлары Хисап палатасы эшчәнлегенең аерым юнәлешләренә җитәкчелек итәләр. Хисап палатасы аудиторларының берәрсе җитәкчелек итә торган Хисап палатасы эшчәнлеге юнәлешенең эчтәлеге Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан билгеләнә.

2. Хисап палатасы аудиторлары үз вазыйфаларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан алты елга билгеләнеп куелалар.

3. Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына кандидатуралар Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (алга таба – Комитет) тарафыннан кертелә. Аудиторлар вазыйфаларына кандидатуралар турындагы тәкъдимнәр Комитетка Хисап палатасы Рәисе тарафыннан бирелә. Хисап палатасы аудиторы вазыйфасына тәкъдим ителгән кандидатура кире кагылган очракта, Комитет ике атна эчендә яңа кандидатура кертә. Монда Комитет Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатураны кабат тәкъдим итәргә йә башка кандидатура кертергә хокуклы.

4. Хисап палатасы аудиторының вакантлы вазыйфасы барлыкка килгәндә, ул ике ай эчендә биләнергә тиеш.

5. Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына кандидатуралар карау тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.

6. Хисап палатасы аудиторлары үзләре җитәкчелек иткән юнәлешләрнең эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен Хисап палатасы Регламенты белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә мөстәкыйль хәл итәләр һәм аның нәтиҗәләре өчен җаваплы булалар.

8 статья. **Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына кандидатураларга таләпләр**

1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына югары белемле һәм дәүләт, муниципаль идарә, дәүләт, муниципаль тикшереп тору (аудит), икътисад, финанс, юриспруденция өлкәсендә кимендә биш ел эш тәҗрибәсенә ия булган Россия Федерациясе гражданнары билгеләнеп куела.

2. Россия Федерациясе гражданы Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары яисә Хисап палатасы аудиторы вазыйфасына түбәндәге очракта билгеләнеп куела алмый:

1) аның хөкем ителгәнлеге кире алынмаган яисә бетмәгән;

2) аны закон көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукый сәләте чикле дип таныган;

3) әгәр вазыйфа биләүгә дәгъва итә торган гражданның вазыйфасы буенча бурычларны үтәве федераль закон белән саклана торган дәүләт серен яисә башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булса, мондый белешмәләрдән файдалану процедурасын узудан баш тарткан;

4) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә чит ил гражданлыгы алган йә Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яшәү хокукы биргән яисә башка документы булган.

3. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче затлар үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының

керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы Президенты Указында билгеләнгән тәртиптә белешмәләр бирергә тиеш.

9 статья. **Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларын биләүче затлар өчен чикләүләр**

1. Вазыйфаларына Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә билгеләнеп куелганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы катнашкан Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары якын туган яисә үз кеше (ата-ана, ир яисә хатын, балалар, ага-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук иренең яисә хатынының ага-энеләре, апа-сеңелләре, ата-аналары һәм балалары) була алмый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә бәйле чикләүләр кагыла.

10 статья. **Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларын биләүче затларның вәкаләтләрен туктату нигезләре**

1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары үз вазыйфаларыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә түбәндәге очракта азат ителәләр:

1) вәкаләтләр чоры тәмамланган;

2) аларга карата судның гаепләү карары законлы көченә кергән;

3) алар законлы көченә кергән суд карары белән хокукый сәләтсез яисә хокукка сәләте чикле дип танылган;

4) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан яисә чит ил гражданлыгы алган йә Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган яшәү хокукы биргән яисә башка төрле документы булган;

5) отставка турында язма гариза биргән;

6) вафат булган;

7) үзләренә йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозган яисә вазыйфаи вәкаләтләрдән явыз ниятләрдә файдаланган, әгәр, вакытыннан алда азат итү турындагы карарны хуплап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелеге тавыш бирсә;

8) 65 яшькә җиткән;

9) әлеге Законның 8 статьясындагы 2 өлешендә, 9 статьясындагы 1 өлешендә каралган хәлләр ачыкланган;

10) законнарда каралган бүтән очракларда.

2. Хисап палатасы Рәисен вазыйфасыннан азат итү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына – Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан, Хисап палатасы Рәисе урынбасарын һәм Хисап палатасы аудиторларын вазыйфаларыннан азат итү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә.

11 статья. **Хисап палатасы Коллегиясе**

1. Хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру, тикшереп тору эшчәнлегенең методологиясе мәсьәләләрен карау, Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә торган хисапларны һәм бәяләмәләрне раслау өчен Хисап палатасы Коллегиясе төзелә.

2. Хисап палатасы Коллегиясе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Хисап палатасы Регламентын кабул итә;

2) Хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча Хисап палатасы аппаратының структурасын һәм штат расписаниесен раслый;

3) Хисап палатасы аудиторлары җитәкчелек итә торган эшчәнлек юнәлешләренең эчтәлеген билгели;

4) Хисап палатасы эшчәнлеге турындагы еллык хисапны раслый;

5) Хисап палатасының эш планнарын раслый;

6) тышкы дәүләт финанс контроле стандартларын һәм тышкы муниципаль финанс контроле стандартларына гомуми таләпләрне раслый;

7) Хисап палатасының тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләре нәтиҗәләре турындагы хисапларны раслый;

8) әлеге Закон һәм Хисап палатасы Регламенты белән каралган бүтән мәсьәләләрне карый.

3. Хисап палатасы Коллегиясе утырышы көн тәртибенә керә торган мәсьәләләр буенча карарлар Хисап палатасы Коллегиясе әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә, тавышлар тигез булганда, Хисап палатасы Рәисе тавышы хәлиткеч була.

4. Хисап палатасы Коллегиясенең эш тәртибе Хисап палатасы Регламенты белән билгеләнә.

12 статья. **Хисап палатасы аппараты**

1. Хисап палатасы аппараты составына инспекторлар һәм бүтән штат хезмәткәрләре керә.

2. Хисап палатасы инспекторларына Хисап палатасы компетенциясе чикләрендә тышкы дәүләт финанс контролен оештыру һәм турыдан-туры уздыру вазыйфалары йөкләнә.

3. Хисап палатасы аппараты хезмәткәрләренең хокуклары, вазыйфалары һәм җаваплылыгы, шулай ук аларның хезмәт итү шартлары дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар, хезмәт законнары, әлеге Закон һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

13 статья. **Хисап палатасы вәкаләтләре**

1. Хисап палатасы түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлешен тикшереп тору;

2) Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларының керемнәр һәм чыгымнар статьяларының күләмнәре, структурасы һәм максатчан билгеләнеше буенча вакытында үтәүне оператив тикшереп торуны оештыру һәм уздыру;

3) Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектын, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары турындагы законнар проектларын, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары турындагы законнарга үзгәрешләр кертү хакындагы законнар проектларын экспертизалау;

4) Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлеше турындагы еллык хисапларны тышкы тикшерү һәм аларның үтәлеше турындагы бәяләмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру;

5) Татарстан Республикасы бюджеты чараларын, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары чараларын һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган бүтән чыганакларны куллануның нәтиҗәлелегенә аудит уздыру, аларны куллануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген (эффектлылыгын һәм экономиялелеген) тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

6) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәткә, шул исәптән акыл эшчәнлегенең сакланылучы нәтиҗәләренә һәм Татарстан Республикасының индивидуальләштерү чараларына, идарәнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору;

7) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәткә идарәнең һәм аның белән эш итүнең нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы бюджетына шушы мөлкәткә идарәдән һәм аның белән эш итүдән чаралар керүне тикшереп тору;

8) Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән салым һәм бүтән ташламаларны һәм өстенлекләрне, бюджет кредитларын бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук дәүләт гарантияләрен һәм поручительлекләрен бирүнең яисә Татарстан Республикасы бюджеты чаралары һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәт исәбеннән юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган алыш-бирешләр буенча башка алымнар белән йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүнең законлылыгын бәяләү;

9) бюджет кредитларын, бюджет инвестицияләрен һәм дәүләт гарантияләрен алучыларның Татарстан Республикасы бюджеты чараларын бирү, алу, максатчан файдалану шартларын үтәүләрен тикшереп тору;

10) Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә (финанс-икътисадый нигезләүләрнең нигезлелеген кертеп), шулай ук Татарстан Республикасының озак сроклы максатчан программаларын финанс-икътисадый экспертизалау;

11) Татарстан Республикасында бюджет процессын анализлау һәм аны камилләштерүгә юнәлгән тәкъдимнәрне әзерләү;

12) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелгән бюджетара трансфертларны файдалануның законлылыгын, нәтиҗәлелеген (эффектлылыгын һәм экономиялелеген) тикшереп тору, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән очракларда җирле бюджетны тикшерү;

13) Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлешенең барышы турында, үткәрелгән тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләрнең нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру;

14) коррупциягә каршы юнәлдерелгән гамәлләрдә вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

15) тышкы дәүләт финанс контроле өлкәсендә Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән бүтән вәкаләтләр.

2. Тышкы дәүләт финанс контроле Хисап палатасы тарафыннан түбәндәгеләргә карата башкарыла:

1) дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлекләр) унитар предприятиеләренә, шулай ук бүтән оешмаларга карата, әгәр алар Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәттән файдалансалар;

2) бүтән оешмаларга карата Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән субсидияләр, кредитлар, гарантияләр алу шартларын үтәүне әлеге чараларны биргән Татарстан Республикасы бюджеты чаралары белән төп эш итүчеләр (эш итүчеләр) һәм аларны алучылар эшчәнлеген тикшереп тору тәртибендә тикшерү юлы белән, әлеге оешмаларны тикшерүләр мөмкинлеге Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән субсидияләр, кредитлар, гарантияләр бирү турындагы шартнамәләрдә билгеләнгән очракларда.

14 статья. **Хисап палатасы тарафыннан тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контролен башкару рәвешләре**

1. Тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле Хисап палатасы тарафыннан тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр рәвешендә башкарыла.

2. Хисап палатасы ревизияләр, тикшеренүләр, нәтиҗәлелеккә аудит рәвешендә тикшереп тору гамәлләре уздыра. Тикшереп тору гамәле уздырганда, Хисап палатасы тарафыннан тиешле акт (актлар) төзелә, ул тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренә җиткерелә. Хисап палатасы акты (актлары) нигезендә хисап төзелә.

3. Эксперт-аналитик гамәлләр кысаларында Хисап палатасы бюджет үтәлешенә экспертизалар, мониторинг, анализ уздыра. Эксперт-аналитик гамәлләрне башкарганда, Хисап палатасы тарафыннан хисап яисә бәяләмә төзелә.

15 статья. **Тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле стандартлары**

1. Тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру өчен тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле стандартлары Хисап палатасы тарафыннан түбәндәгеләргә карата раслана:

1) дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә һәм Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлекләр) унитар предприятиеләренә карата – Россия Федерациясе Хисап палатасы тарафыннан расланган гомуми таләпләр нигезендә;

2) бүтән оешмаларга карата – федераль закон белән билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә.

2. Тышкы дәүләт финанс контроле стандартларын әзерләгәндә, дәүләт контроле, аудит һәм финанс хисаплылыгы өлкәсендәге халыкара стандартлар исәпкә алына.

3. Хисап палатасы тышкы муниципаль финанс контроле стандартларына гомуми таләпләрне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары өчен әзерләргә хокуклы.

4. Тышкы дәүләт финанс контроле стандартлары Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килә алмый.

16 статья. **Хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру**

1. Хисап палатасы үз эшчәнлеген үзе мөстәкыйль әзерли һәм раслый торган еллык планнар нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр нәтиҗәләрен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре һәм гарызнамәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре һәм гарызнамәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан кергән көненнән 10 көнлек срокта карала.

4. Хисап палатасы эшчәнлеге планнарын формалаштырганда, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының һәм комиссияләренең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гарызнамәләре һичшиксез каралырга тиеш.

5. Еллык план проекты Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан карала һәм раслана.

6. Планнан тыш тикшереп тору гамәлләре Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы депутатларының гомуми саныннан кимендә биштән бере мөрәҗәгате буенча яисә Хисап палатасы Коллегиясе карары нигезендә уздырыла.

17 статья. **Хисап палатасы Регламенты**

Хисап палатасы эшчәнлеге юнәлешләренең эчтәлеге, Хисап палатасы Рәисе урынбасары белән аудиторлары арасында вазыйфаларны бүлү, Хисап палатасы аппараты структур бүлекчәләренең функцияләре һәм үзара хезмәттәшлеге, эшләр алып бару тәртибе, тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр әзерләү һәм уздыру һәм Хисап палатасы эчке эшчәнлегенең бүтән мәсьәләләре Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан раслана торган Хисап палатасы Регламенты белән билгеләнә.

18 статья. **Хисап палатасы вазыйфаи затлары таләпләрен үтәү мәҗбүрилеге**

1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары һәм Хисап палатасы инспекторлары Хисап палатасының вазыйфаи затлары була.

2. Хисап палатасының вазыйфаи затларының аларның Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән вазыйфаи вәкаләтләрен башкаруга бәйле таләпләре һәм гарызнамәләре тышкы дәүләт финанс контроле үткәрелә торган дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт органнары, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар, оешмалар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри була.

3. Хисап палатасы вазыйфаи затларының законлы таләпләрен һәм гарызнамәләрен үтәмәү, шулай ук үзләренә йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрен башкаруга каршылык күрсәтү Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

19 статья. **Хисап палатасы вазыйфаи затларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы**

1. Хисап палатасы вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вазыйфаи вәкаләтләрен башкарганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерелә торган органнар һәм оешмалар били торган территориягә һәм биналарга каршылыксыз кереп йөрергә, аларның документларыннан һәм материалларыннан файдаланырга, шулай ук алар били торган территорияне һәм биналарны карап чыгарга;

2) охшатып ясаулар, ялган күчермәләр, урлаулар, явыз ният белән кулланулар ачылган очракта һәм әлеге хокукка каршы гамәлләрне кисәтү зарурлыгы булганда, тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның кассаларын, касса һәм хезмәт урыннарын, складларын һәм архивларын мөһерләп бикләп куярга, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрне исәпкә алып, документларын һәм материалларын алырга. Кассаларны, касса һәм хезмәт урыннарын, складларны һәм архивларны мөһерләп бикләп кую, документларны һәм материалларны алу тикшерелә торган органнарының һәм оешмаларның вәкаләтле вазыйфаи затлары катнашында һәм тиешле актлар төзеп башкарыла;

3) үз компетенцияләре чикләрендә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм аларның структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт органнары, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар, оешмалар вазыйфаи затларына гарызнамаләр җибәрергә;

4) үз компетенцияләре чикләрендә тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләреннән һәм башка вазыйфаи затларыннан тикшереп тору гамәлләре уздырганда ачылган хокук бозулар фактлары буенча язма аңлатмалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның кирәкле күчермәләрен таләп итәргә;

5) тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан тикшереп тору гамәлләре уздырганда соратып алынган документларның һәм материалларның тапшырылмау яисә вакытында тапшырылмау фактлары буенча актлар төзергә;

6) тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы барлык кирәкле документлар белән, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган документлар белән, үз компетенцияләре чикләрендә танышырга;

7) тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүмат белән һәм тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның күрсәткечләр базаларындагы электрон рәвештәге мәгълүмат белән, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә дәүләт, хезмәт, коммерция серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган мәгълүмат белән танышырга;

8) белешмәләрнең электрон базаларына техник документация белән танышырга;

9) административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, әгәр мондый хокук Россия Федерациясе законнарында каралган булса.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган очракта кассалар, касса һәм хезмәт урыннары, складлар һәм архивлар мөһерләнеп бикләп куелганда, документлар һәм материаллар алынганда, Хисап палатасының вазыйфаи затлары Хисап палатасы Регламентында билгеләнгән тәртиптә бу хакта кичекмәстән (24 сәгать эчендә) Хисап палатасы Рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

3. Хисап палатасының вазыйфаи затлары тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның оператив-хуҗалык эшчәнлегенә тыкшынырга, шулай ук тикшереп тору гамәлләре уздырганда алынган мәгълүматны фаш итәргә, тикшереп тору гамәлләре тәмамланганчы һәм тиешле актлар һәм хисаплар төзелгәнче үз нәтиҗәләрен хәбәр итәргә хокуклы түгел.

4. Хисап палатасының вазыйфаи затлары тикшерелә торган органнарда һәм оешмаларда тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздырганда үзләренә мәгълүм булган дәүләт, хезмәт, коммерция серен һәм закон белән саклана торган башка серне сакларга, тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләрне объектив рәвештә уздырырга һәм аларның нәтиҗәләрен Хисап палатасының тиешле актларында, хисапларында һәм бәяләмәләрендә дөрес чагылдырырга тиеш.

5. Хисап палатасының вазыйфаи затлары үзләре уздыра торган тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр нәтиҗәләренең дөреслеге һәм объективлыгы өчен, шулай ук дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

6. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары һәм Хисап палатасы аудиторлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның комитетлары, комиссияләре һәм эш төркемнәре утырышларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнары утырышларында, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы координация һәм киңәш органнары утырышларында катнашырга хокуклы.

20 статья. **Хисап палатасына мәгълүмат тапшыру**

1. Хисап палатасы үзләренә карата тышкы дәүләт финанс контролен гамәлгә ашырырга хокуклы булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт органнары, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары белән идарә итүче органнар, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар, оешмалар, аларның вазыйфаи затлары, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм аларның структур бүлекчәләре Хисап палатасына аның үтенечләре буенча 14 көн эчендә тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру өчен кирәкле документларны һәм материалларны тапшырырга тиеш.

2. Хисап палатасының Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре һәм гарызнамәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәләре нигезендә тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру кысаларында җибәрелгән гарызнамәләренә җавапларның срогы җиде көннән кимрәк билгеләнергә мөмкин.

3. Хисап палатасы гарызнамәсендә тикшерелә торган органның яисә оешманың исеме, кирәкле мәгълүмат, документлар, материаллар күрсәтелергә тиеш. Хисап палатасы гарызнамәсе Хисап палатасы бланкында рәсмиләштерелә, Хисап палатасының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана. Гарызнамә тикшерелә торган орган яисә оешма урнашкан урынга почта буенча йә санлы электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә йә тикшерелә торган органга яисә оешмага турыдан-туры тапшырыла.

4. Хисап палатасы үзенә элегрәк бирелгән мәгълүматны, документларны һәм материалларны кабат соратып алырга хокуклы түгел.

5. Хисап палатасы тикшереп тору гамәлләрен тормышка ашырганда, тикшерелә торган органнар һәм оешмалар Хисап палатасының вазыйфаи затларына идарәчел һәм башка хисаплылык белән, Татарстан Республикасы бюджетын, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларын, җирле бюджетларны төзүгә һәм үтәүгә бәйле документация һәм документлар белән танышу, тикшерелә торган оешмалар куллана торган Татарстан Республикасы дәүләт милкеннән, муниципаль берәмлекләр милкеннән, мәгълүмат системаларыннан һәм аларга техник документациядән, шулай ук Хисап палатасына үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка документлардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының дәүләт унитар предприятиеләрен, учреждениеләрне төзү, үзгәртеп кору яисә бетерү турындагы, хуҗалык ширкәтләренең устав капиталларында Татарстан Республикасы акцияләренең һәм өлешләренең санын үзгәртү турындагы, бюджет чараларына идарә итү һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге башка объектлар белән идарә итү хакында шартнамәләр төзү турындагы карарлары кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә Хисап палатасына җибәрелә.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Хисап палатасына Татарстан Республикасы бюджет хисаплылыгын, расланган җыелма бюджет язмасын һәм аларга үзгәрешләрне җибәрә.

8. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары Хисап палатасына дәүләт унитар предприятиеләренең, учреждениеләрнең, шулай ук Татарстан Республикасының катнашу өлеше кимендә 50 процент булган акционер җәмгыятьләрнең эшчәнлегенә аудитор тикшерүләре нәтиҗәләре буенча хисапларны һәм аудитор оешмалары бәяләмәләрен алар имзаланган көннән соң 30 көн эчендә җибәрә.

9. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органнар һәм оешмалар тарафыннан Хисап палатасына аның гарызнамәләре буенча тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр уздыру өчен кирәкле мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшырылмаган яисә вакытында тапшырылмаган өчен, шулай ук мәгълүматны, документларны һәм материалларны тулы күләмдә тапшырмаган яисә дөрес булмаган мәгълүмат, документлар һәм материаллар тапшырган өчен Россия Федерациясе законнарында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарында каралган җаваплылык билгеләнә.

21 статья. **Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен оператив тикшереп тору**

1. Хисап палатасы Татарстан Республикасы бюджетын үтәү барышында акчаларның тулысынча һәм вакытында керүен, Татарстан Республикасы бюджетының закон белән расланган күрсәткечләре белән чагыштырганда бюджет ассигнованиеләренең фактта тотылуын тикшереп тора, тайпылышларны һәм бозуларны ачыклый, аларны анализлый, аларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертә.

2. Хисап палатасы квартал саен Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең барышы турында мәгълүмат тапшыра, анда керемнәрне формалаштыру һәм Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда агымдагы елга расланган күрсәткечләр буенча тотылган чыгымнар турында һәм бюджет процессында катнашучыларның гамәлдәге законнарны үтәүләре турында хакыйкый белешмәләр китерелә.

3. Оператив тикшереп тору белешмәләре ревизияләр һәм тикшерүләр планлаштырганда файдаланыла.

22 статья. **Ревизияләр һәм тикшерүләр**

1. Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлешен тикшереп тору кысаларында Хисап палатасы комплекслы ревизияләр һәм тематик тикшерүләр уздыра. Ревизияләр һәм тикшерүләр тикшерелә торган объектлар урнашкан урында уздырыла. Аларны уздыру сроклары, аларның күләмнәре һәм ысуллары Хисап палатасы тарафыннан билгеләнә.

2. Ревизияләр һәм тикшерүләр уздыру барышында җитештерү-хуҗалык эшчәнлегенең законлылыгын, бухгалтерлык исәбенең һәм финанс хисабының дөреслеген документаль раслау нигезендә тикшерелә торган объект белән Татарстан Республикасы бюджеты арасындагы үзара түләүләрнең вакытында һәм тулы башкарылуы билгеләнә.

3. Ревизия яисә тикшерү уздыру йомгаклары буенча хисап төзелә, аның дөреслеге өчен Хисап палатасының тиешле вазыйфаи затлары шәхсән җаваплы булалар.

4. Уздырылган ревизияләрнең һәм тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында, шул исәптән дәүләткә китерелгән зыян турында, һәм ачыкланган закон бозулар турында Хисап палатасы Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итә, аларны тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләренә җиткерә.

5. Контроль чаралар уздырганда Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары акчаларын законсыз тоту фактлары ачыкланса һәм аларда җинаятьчел яисә коррупциячел хокук бозу билгеләре булган очракта, Хисап

палатасы контроль чаралар материалларын билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән хокук саклау органнарына тапшыра.

6. Хисап палатасының вазыйфаи затлары һәм аның эшенә җәлеп ителгән белгечләр ревизияләр һәм тикшерүләр барышында алынган белешмәләрне бары тик Хисап палатасы кушуы буенча эшләр башкарганда гына файдаланырга мөмкин.

23 статья. **Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычының торышын һәм кредит ресурсларыннан файдалануны тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора:

1) Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычына идарә итүне һәм хезмәт күрсәтүне;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан чит дәүләтләрдән һәм финанс оешмаларыннан алына торган чит ил кредитларыннан һәм заемнарыннан законлы, рациональ һәм нәтиҗәле файдалануны;

3) кире кайтару шарты белән бирелә торган үзәкләштерелгән финанс ресурсларын нәтиҗәле урнаштыруны;

4) чит дәүләтләргә һәм халыкара оешмаларга бушлай бюджет кредитлары, дәүләт гарантияләре, шулай ук кире кайтармау шарты белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары бирелүне.

24 статья. **Банк системасын тикшереп тору**

Хисап палатасы түбәндәгеләрне тикшереп тора:

1) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларына хезмәт күрсәтү өлешендә банклар һәм башка кредит оешмалары эшчәнлеген;

2) Татарстан Республикасының дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү буенча банклар һәм башка кредит оешмалары эшчәнлеген.

25 статья. **Хисап палатасы тәкъдимнәре һәм күрсәтмәләре**

1. Хисап палатасы контроль чаралар уздыру нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, тикшерелә торган органнарга һәм оешмаларга, аларның вазыйфаи затларына карау һәм ачыкланган хокук бозуларны һәм кимчелекләрне бетерү буенча, Татарстан Республикасына, муниципаль берәмлеккә матди зыян килүне булдырмый калу яисә китерелгән зыянны каплау буенча, хокук бозуларда гаепле вазыйфаи затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өчен, шулай ук хокук бозуларга чик кую, аларны бетерү һәм кисәтү чараларын күрү өчен тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

2. Хисап палатасының тәкъдиме Хисап палатасы Рәисе йә аның урынбасары тарафыннан имзалана.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм муниципаль органнар,

тикшерелә торган органнар һәм оешмалар тәкъдимне алган көннән бер ай эчендә тәкъдимне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлар һәм күрелгән чаралар турында Хисап палатасына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

4. Чик кую һәм кисәтү буенча кичекмәстән чаралар күрүне таләп итә торган хокук бозулар ачыкланган очракта, шулай ук Хисап палатасының вазыйфаи затлары тарафыннан контроль чаралар уздыруга тоткарлык тудырылган очракта, Хисап палатасы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль органнарга, тикшерелә торган органнарга һәм оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына күрсәтмә җибәрә.

5. Хисап палатасының күрсәтмәсендә конкрет хокук бозулар һәм күрсәтмә чыгаруның конкрет нигезләре күрсәтелергә тиеш. Хисап палатасының күрсәтмәсе Хисап палатасы Рәисе йә аның урынбасары тарафыннан имзалана.

6. Хисап палатасының күрсәтмәсе анда билгеләнгән срокларда үтәлергә тиеш.

7. Хисап палатасының күрсәтмәсен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнарында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарында каралган җаваплылык билгеләнә.

26 статья. **Хисап палатасы экспертизасы һәм бәяләмәсе**

1. Хисап палатасы түбәндәгеләргә экспертиза ясый һәм бәяләмә бирә:

1) Татарстан Республикасы бюджеты проектына, шул исәптән аның керем һәм чыгым статьяларының нигезләнгән булуына, Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт бурычы һәм бюджеты кытлыгы күләмнәренә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапка;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты өчен хокукый нәтиҗәләргә китерә торган закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар проектларына, Татарстан Республикасы шартнамәләре һәм килешүләре проектларына;

4) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау күздә тотыла торган озак сроклы максатчан программалар проектларына.

2. Үз компетенциясенә керә торган башка мәсьәләләр буенча Хисап палатасы түбәндәгеләр нигезендә бәяләмәләр яисә язма җаваплар әзерләүне һәм тапшыруны гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле карарлар белән рәсмиләштерелгән йөкләмәләре;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары һәм комиссияләре гарызнамәләре;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары гарызнамәләре;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гарызнамәләре;

6) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары гарызнамәләре.

3. Гарызнамәне карау һәм бәяләмә әзерләү турында яисә аннан баш тарту турында карар Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан кабул ителә. Баш тарту очрагында Хисап палатасы Рәисе гарызнамәне сәбәбен күрсәтеп кире кайтара.

4. Хисап палатасы бәяләмәләрендә аның карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары тарафыннан кабул ителә торган карарларның сәяси чагылышы булмаска тиеш.

27 статья. **Тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның хокукларына гарантияләр**

1. Контроль чаралар уздырганда Хисап палатасы тарафыннан төзелгән актлар тикшерелә торган органнарның һәм оешмаларның җитәкчеләренә җиткерелә. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең актны алган көннән җиде эш көне эчендә тапшырылган аңлатмалары һәм искәрмәләре актларга теркәлеп куелалар һәм алга таба аларның аерылмас өлеше булалар.

2. Тикшерелә торган органнар һәм оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары Хисап палатасының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

28 статья. **Контроль чараларның нәтиҗәләрен анализлау**

Татарстан Республикасында бюджет процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү кысаларында Хисап палатасы үткәрелгән контроль чараларының нәтиҗәләрен системалы рәвештә анализлый һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру һәм бюджет акчаларын тоту процессында ачыкланган читкә тайпылуларның һәм хокук бозуларның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен берләштерә һәм алар буенча тикшерү алып бара.

29 статья. **Хисап палатасы вазыйфаи затларының статусына гарантияләр**

1. Хисап палатасының вазыйфаи затларына үзләренең вазыйфаи вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга каршылык тудыру яисә алар кабул итә торган карарларга йогынты ясау максатларында нинди дә булса рәвештә тәэсир итү, шулай ук Хисап палатасының вазыйфаи затларына карата көч кулланулар, кимсетүләр, яла ягулар йә аларның эшчәнлеге турында ялган мәгълүмат тарату Россия Федерациясе законнарында һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

2. Хисап палатасының вазыйфаи затлары судьяларны, хокук саклау һәм контроль органнарының вазыйфаи затларын дәүләт яклавы турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт яклавында булалар.

3. Хисап палатасының вазыйфаи затлары һөнәри бәйсезлек гарантияләренә ия.

30 статья. **Хисап палатасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Хисап палатасы эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла һәм аңа йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итәрлек күләмдә күздә тотыла.

2. Хисап палатасын тотуга акчалар Татарстан Республикасы бюджетында аерым юл белән карала. Финанс елы барышында Хисап палатасын тотуга бюджет ассигнованиеләре күләмен Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда билгеләнгән күләмнән киметү рөхсәт ителми.

3. Хисап палатасы тарафыннан бюджет акчаларын тотуны, Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән файдалануны тикшереп тору Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

31 статья. **Хисап палатасының вазыйфаи затларын һәм башка хезмәткәрләрен матди һәм социаль яктан тәэмин итү**

1. Хисап палатасы Рәисенә Татарстан Республикасы Премьер-министры беренче урынбасарының айлык акчалата гомуми түләве һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве күләмнәрендә айлык акчалата гомуми түләү һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве билгеләнә.

2. Хисап палатасы Рәисе урынбасарына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарының айлык акчалата гомуми түләве һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве күләмнәрендә айлык акчалата гомуми түләү һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве билгеләнә.

3. Хисап палатасы аудиторларына Татарстан Республикасы министрының айлык акчалата гомуми түләве һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве күләмнәрендә айлык акчалата гомуми түләү һәм айлык акчалата кызыксындыру түләве билгеләнә.

4. Хисап палатасы аппаратындагы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратындагы тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары дәрәҗәсендә билгеләнә. Вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр һәм башка түләүләр дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм күләмнәрдә билгеләнә.

5. Хисап палатасы аппаратының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының шундый ук хезмәткәрләре өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

6. Хисап палатасы Рәисенә, Хисап палатасы Рәисе урынбасарына һәм Хисап палатасы аудиторларына Татарстан Республикасы законнарында дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар өчен билгеләнгән медицина хезмәте күрсәтелә һәм башка гарантияләр бирелә.

7. Хисап палатасы аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләренә дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән медицина хезмәте күрсәтелә һәм башка гарантияләр бирелә.

32 статья. **Хисап палатасының тышкы багланышлары**

1. Хисап палатасы, үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе башка субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, Россия Федерациясе Үзәк банкының территориаль идарәләре, Федераль казначылыкның территориаль органнары, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең салым органнары, прокуратура органнары, башка хокук саклау, күзәтчелек һәм контроль органнары белән хезмәттәшлек итәргә хокуклы. Хисап палатасы алар белән хезмәттәшлек һәм үзара багланышлар турында килешүләр төзергә хокуклы.

2. Хисап палатасы Россия Федерациясенең контроль-хисап органнары берләшмәләренә (ассоциацияләренә), Татарстан Республикасының контроль-хисап органнары берләшмәләренә (ассоциацияләренә) керергә хокуклы.

3. Хисап палатасы чит федератив дәүләтләр субъектларының, шулай ук чит дәүләтләрнең алминистратив-территориаль берәмлекләренең хисап һәм контроль палаталары һәм парламент контроле органнары белән, аларның халыкара берләшмәләре белән багланышлар урнаштырырга, алар белән хезмәттәшлек һәм үзара багланышлар турында килешүләр төзергә, финанс контроле органнарының күрсәтелгән халыкара берләшмәләренә керергә хокуклы.

4. Үз эшчәнлеген җайга салу максатларында Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары вакытлы һәм даими эшләүче координация, консультация, киңәшләшү һәм шулай ук башка эш органнары оештырырга мөмкин.

5. Хисап палатасы Россия Федерациясе башка субъектларының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарының язма мөрәҗәгате нигезендә алар уздыра торган тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләрдә катнашырга мөмкин.

6. Хисап палатасы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары белән, шул исәптән тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә уртак тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр үткәргәндә, үзара багланышлар урнаштырырга;

2) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарына оештыру, хокукый, мәгълүмати, методик һәм башка ярдәм күрсәтергә;

3) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары хезмәткәрләренә һөнәри әзерлек, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү буенча ярдәм итәргә;

4) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары белән берлектә уртак тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр планлаштырырга һәм аларны үткәрүне оештырырга;

5) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле

органнары мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары эшчәнлегенә анализ ясарга һәм алар эшенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча рекомендацияләр бирергә.

33 статья. **Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап һәм мәгълүмат бирү**

1. Хисап палатасы үткәрелгән тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр турында, аларны үткәрү барышында ачыкланган хокук бозулар турында, кертелгән тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр турында, шулай ук алар буенча кабул ителгән карарлар һәм күрелгән чаралар турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – "Интернет" челтәре) рәсми сайтта үз эшчәнлеге турында мәгълүматның ачык булуын тәэмин итү максатларында мәгълүмат урнаштыра.

2. Хисап палатасы үз эшчәнлеге турында ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисап бирә. Әлеге хисап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында каралганнан соң гына, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла яисә "Интернет" челтәрендә урнаштырыла. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Хисап палатасының аерым тикшереп тору һәм эксперт-аналитик гамәлләр нәтиҗәләре буенча хисаплары кертелергә мөмкин.

3. Хисап палатасы квартал саен Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үз эшчәнлеге хакында мәгълүмат тапшыра.

4. Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм "Интернет" челтәрендә урнаштыру Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Хисап палатасы Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2011 елның 1 октябреннән үз көченә керә.
2. "Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында" 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 өлеше, 6 статьясындагы 1 өлеше, 7 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вәкаләтләре вакыты өлешендә әлеге Закон үз көченә кергәннән соң вазыйфага билгеләнеп куелган Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторларына карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№65-ТРЗ